ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.01.2022 г. Заинск № 01

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышы мониторингын үткәрү тәртибен раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, РФ Энергетика министрлыгының «Ягулык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышы мониторингын үткәрү тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
(85558) 7-08-18

Кушымта
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
10. 01. 2021 ел
01 номерлы карары белән
расланган.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышы мониторингын үткәрү тәртибе**

1. Әлеге тәртип муниципаль берәмлек территориясендә җылылык белән тәэмин итү системаларының торышын мониторинглау системасын булдырганда һәм эшләгәндә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәре оешмаларының үзара эшчәнлек механизмын билгели.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системасы торышы мониторинг системасы - җылылык челтәрләрен, котельныйлар җиһазларын күзәтү, бәяләү һәм аларның торышын фаразлауның комплекслы системасы ул (алга таба - мониторинг системасы).

Җылылык белән тәэмин итү мониторингы системасын булдыру һәм аны эшләтүнең максаты булып, җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру, авария хәлләрен кисәтү, булдырмау, ачыклау һәм бетерү чараларын гамәлгә ашыру ярдәмендә авария-торгызу эшләрен башкаруга чыгымнарны киметү тора.

2. Мониторинг системасының төп бурычлары булып тора:

- җылылык белән тәэмин итү объектларының торышы, җылылык белән тәэмин итү системаларында аварияләлек һәм аларда үткәрелә торган ремонт эшләре турында статистик мәгълүматларны җыю, эшкәртү һәм анализлау;

- җылылык белән тәэмин итү объектларында ремонт эшләрен башкару планнарын төзү процессын оптимальләштерү;

- җылылык белән тәэмин итү объектларын карап тотуга һәм ремонт эшләрен үткәрүгә финанс чаралары бүлеп бирүне нәтиҗәле планлаштыру.

2.1. Җылылык белән тәэмин итү системаларын үстерү мониторингы өчен кулланыла торган төп индикаторлар булып тора:

- җылылык энергиясен эшләп чыгару күләме;

- җылылык чыганаклары егәрлекләрен йөкләү дәрәҗәсе;

- җылылык куәтләренең җылылык энергиясен кулланучылар ихтыяҗларына туры килү дәрәҗәсе;

- каралган чор өчен җылылык энергиясенең 1 кв. метрга чагыштырма чыгымы;

- җылылык энергиясен эшләп чыгаруга ягулык чыгымының чагыштырма нормалары;

- җылылык энергиясен җитештерүгә ресурсларның чагыштырма чыгымы;

- җылылык энергиясен транспортлауга ресурсларның чагыштырма чыгымы;

- җылылык белән тәэмин итү системаларының авариялелеге (челтәрләрнең бер километр озынлыгына берәмлек);

- кулланучыларның түләү дәрәҗәсе;

- рентабельлелек дәрәҗәсе.

3. Мониторинг системаларының эшләве объект дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә башкарыла.

Объект дәрәҗәсендә оештыру-методик җитәкчелекне һәм мониторинг системасы эшчәнлеген координацияләүне җылылык белән тәэмин итү объектларын эксплуатацияләүче оешмалар гамәлгә ашыра.

Муниципаль дәрәҗәдә оештыру-методик җитәкчелекне һәм мониторинг системасы эшчәнлеген координацияләүне Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының ресурслар белән тәэмин итүче оешмалары гамәлгә ашыра.

4. Мониторинг системасы үз эченә ала:

- мәгълүмат җыю;

- мәгълүматларны саклау, эшкәртү һәм тапшыру;

- карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү.

4.1. Мәгълүмат җыю.

Җылылык белән тәэмин итү объектларының торышын күзәтү буенча мәгълүмат җыю системасы муниципаль берәмлек территориясендә җылылык челтәрләрен, җылылык казаннары җайланмаларын күзәтүнең гамәлдәге барлык ысулларын берләштерә. Мәгълүмат җыю системасына башкарылган ремонт буенча мәгълүматлар һәм эксплуатация персоналы туплаган белешмәләр кертелә.

Түбәндәге мәгълүматлар җыела:

• технологик җиһазларның һәм җылылык челтәрләрен салу (төзү) буенча мәгълүматларның паспорт базасы;

• салынган җылылык челтәрләре буйлап 5 метрлы зонада катнаш коммуникацияләрнең урнашуы, дренаж һәм канализация челтәрләре схемасы;

- (җылылык үткәргечләрнең, ЦТП, котельныйларның аксонометрик, принципиаль схемалары);

- җылылык белән тәэмин итү объектларында үткәрелгән ремонт эшләре турында мәгълүматлар;

- җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, киңәйтү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазлау тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру турында мәгълүматлар;

- объектның исемен, объектның адресын, авария хәленә китергән сәбәпләрне, авария хәлен бетерү буенча кабул ителгән чараларны, шулай ук кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүдән өзгәндә, өзелү вакытында һәм җылылык бирелмәгән кулланучыларның исемлеген күрсәтеп, җылылык белән тәэмин итү объектларында барлыкка килә торган авария хәлләрен

исәпкә алу реестры,

- салынган җылылык челтәрләре зонасында грунт турында мәгълүматлар.

Мәгълүматларны җыю кәгазь чыганакларда һәм электрон рәвештә җылылык белән тәэмин итү объектларын эксплуатацияләүче оешмаларда, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетында оештырыла.

4.2. Мәгълүматларны саклау, эшкәртү һәм тапшыру.

Мониторинг материаллары кәгазь чыганакларда һәм электрон рәвештә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетында, шулай ук җылылык белән тәэмин итү объектларын эксплуатацияләүче оешмаларда биш елдан да ким булмаган вакыт саклана.

Мәгълүмат әлеге мониторингның җыелган мәгълүматлар базасыннан гарызнамә буенча кызыксынган затларга бирелергә мөмкин.

4.3. Карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү.

Җылылык белән тәэмин итү объектларының торышы турында мәгълүмат анализлау һәм бирү системасы, зыян күргән иң ышанычсыз объектларны сайлап алу нигезендә финанслауның бирелгән күләменнән чыгып, ремонт планнарын оптимальләштерү бурычын хәл итүгә юнәлдерелгән.

Мәгълүматларны анализлау җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәре оешмалары белгечләре, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты белгечләре тарафыннан йөкләнгән вәкаләтләр өлешендә һәм алга таба мәгълүматлар базасын саклау өчен башкарыла. Мәгълүматлар базасын анализлау нигезендә тиешле карарлар кабул ителә.

Ремонт чорында җылылык челтәрләрен ремонтлау һәм кабат салуны диагностикалауның һәм планлаштыруның төп методы буларак кулланыла торган опрессовка нәтиҗәләре мәгълүматларны статистик эшкәртү өчен төп мәгълүмат чыганагы булып тора.

Мониторинг мәгълүматлары объектның чын халәтен ачыклау, ялган мәгълүмат булдырмау һәм оптималь карар кабул итү максатларында объектның актуаль паспорт характеристикаларына салына.